**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2015 ел, 18 июль № 528

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрешне су белән тәэмин итү өчен файдаланылучы су объектларының санитария саклык зоналары проектларын раслау тәртибе турында» 2012 ел, 29 февраль, 177 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итү өчен файдаланылучы су объектларының санитария саклык зоналары проектларын раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә эчә торган һәм хуҗалык-көнкүрешне су белән тәэмин итү өчен файдаланылучы су объектларының санитария саклык зоналары проектларын раслау тәртибе турында» 2012 ел, 29 февраль, 177 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 30 июль, 646 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә кулланыла торган су белән тәэмин итү өчен файдаланылучы су объектларының санитария саклык зоналары проектларын раслау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктта:

4 нче пунктчага «Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрында хокук теркәлмәгән, » сүзләрен өстәргә;

6 нчы пунктча үз көчен югалткан дип санарга;

4 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 3 нче һәм 4 нче пунктчалар өстәргә:

«3) зоналар проектының санитария кагыйдәләренә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе күчермәсен;

4) Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрында хокук теркәлгән, су объекты санитария саклык зоналарының беренче поясы урнашкан җир кишәрлегенә хокук билгели торган документлар күчермәсен.»;

7 нче пунктка «җитәкче имзасы һәм оешма мөһере белән (юридик затлар өчен)» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе законнары белән мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда.»;

8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Гариза бирүче бу Тәртипнең 3 нче пунктында күздә тотылган документларның тулы булмаган комплектын тапшырган, Зоналар проектының «Эчәргә яраклы су белән тәэмин итү чыганакларының һәм суүткәргечләрнең санитария саклык зоналары. СанПиН 2.1.4.1110-02» санитария кагыйдәләре һәм нормалары белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән, гариза бирүче тапшырган документларда дөрес булмаган мәгълүматлар булган очракта, Министрлык биш эш көне эчендә, кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, документларны гариза бирүчегә кире кайтара.»;

9 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеген саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә – зоналар проектының санитария кагыйдәләренә туры килүе турында санитария-эпидемиология бәяләмәсе күчермәсен кертү хакында;

Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә – су объекты санитария саклык зоналарының беренче поясы урнашкан җир кишәрлегенә хокуклар турында Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр кертү хакында.»;

10 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Әлеге Тәртипнең 9 нчы пункты нигезендә үтенечнамә җибәрелгән органнан гариза бирүчедә соратылган документларның булмавы турында мәгълүмат алган очракта, Министрлык аны алган көннән биш эш көне эчендә зоналар проектын раслаудан баш тарта һәм бу хакта гариза бирүчегә хәбәр итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков